ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

27 декабрь, 2021 ел № 11/8

Яр Чаллы шәһәренең җирле узидарә органнарында муниципаль вазыйфаларны даими нигездә биләүче затларны мәҗбүри дәүләт иминләштерүе турында нигезләмәне раслау хакында

«Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутаты, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты вәкаләтләрен гамәлгә ашыру гарантияләре турында» 2009 елның 12 февралендәге 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә

Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. Яр Чаллы шәһәренең җирле узидарә органнарында муниципаль вазыйфаларны даими нигездә биләүче затларны мәҗбүри дәүләт иминләштерүе турында нигезләмәне кушымта нигезендә расларга.

2. Әлеге Карарның үтәлешен контрольдә тотуны Шәһәр Советының социаль-икътисадый үсеш мәсьәләләре һәм бюджет буенча даими комиссиясенә, Контроль-хисап палатасы Рәисе Т.В. Шливега йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев

ГОРОДСКОЙ СОВЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ ШӘҺӘР СОВЕТЫ
ПРОТОКОЛЬНАЯ ЧАСТЬ
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ

Шәһәр Советының
11/8 Карарына кушымта
27 декабрь, 2021 ел

Яр Чаллы шәһәренең җирле узидарә органнарында муниципаль вазыйфаларны даими нигездә биләүче затларны мәҗбүри дәүләт иминләштерүе турында нигезләмә

1. Әлеге нигезләмә даими нигездә муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның (алга таба - муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар) сәламәтлегенә зыян килгән очракта, аларның гомерен һәм сәламәтлеген мәҗбүри дәүләт иминләштерүе буенча түләү очракларын, тәртибен һәм күләмнәрен билгели.

2. Муниципаль вазыйфаны биләгән затның гомере һәм сәламәтлеге муниципаль вазыйфага билгеләнгән көннән башлап вазыйфадан азат ителгән көнгә кадәр исәпләнә торган чорда мәҗбүри дәүләт иминәштерүе узарга тиеш.

3. Мәҗбүри дәүләт иминияте буенча иминләштерүчеләр булып Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең муниципаль вазыйфа биләнүче җирле үзидарә органнары тора.

4. Иминләштерүчеләрне сайлап алу дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында Россия Федерациясе законында каралган тәртиптә гамәлгә ашырыла.

5. Мәҗбүри дәүләт иминияте килешүе (алга таба ─ иминият килешүе) иминләштерүче һәм иминиятче арасында, иминләштерелүче зат (файда күрүче) файдасына Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә, тәүлегенә 24 сәгать дәвамында иминият яклавы белән бер календарь елга төзелә.

Иминиятләштерүче тарафыннан иминият килешүендә әлеге нигезләмәнең 7 пунктында күрсәтелгән иминият очраклары өчен файда күрүчеләр даирәсе билгеләнә.

Иминият килешүендә иминләштерүче тарафыннан мәҗбүри тәртиптә файда күрүчеләр сыйфатында түбәндәгеләр аталырга тиеш:

1) иминләштерелгән затның вафат булган көненә аның белән никахы теркәлгән ире (хатыны);

2) иминләштерелгән затның ата-анасы (уллыкка алучылары), иминләштерелгән затның бабасы һәм әбисе ─ иминләштерелгән затның ата-анасы булмаган, һәм алар аны кимендә өч ел тәрбияләгән яки караган очракта;

3) иминләштерелгән затның үги атасы яки үги анасы ─ алар аны кимендә биш ел тәрбияләгән яки караган очракта;

4) иминләштерелгән затның 18 яшькә җитмәгән яки аннан өлкәнрәк, әмма 18 яшькә кадәр инвалид булган, шулай ук оештыру-хокукый формаларына һәм милек рәвешләренә бәйсез рәвештә белем бирү оешмаларында белем алучы, белем алулары тәмамланганчы, ләкин 23 яшькә җитмәгән балалары;

5) иминләштерелгән зат тарафыннан опекага алынган балалар.

Иминият килешүендә файда күрүчеләр иминләштерүче тарафыннан билгеләнгән тәртиптә, муниципаль вазыйфаны биләүче зат тарафыннан бирелә торган мәгълүмат нигезендә күрсәтелә. Иминият килешүендә файда күрүчеләр

күрсәтелмәгән очракта, файда күрүчеләр дип, граждан законнарында билгеләнгән тәртиптә, иминләштерелгән затның варислары танылa.

6. Төзелгән иминият килешүенең гамәлдә булу срогы чыкканчы затны муниципаль вазыйфаны биләүдән азат иткәндә, муниципаль вазыйфадан азат иткән көннән башлап күрсәтелгән затка карата иминият килешүенең гамәлдә булуы туктатыла. Күрсәтелгән нигез буенча муниципаль вазыйфаны биләп торучы затка карата иминият килешүенең гамәлдә булуы срогыннан алда туктатылган очракта, иминиятче әлеге нигезләмәнең 12 пунктында билгеләнгән тәртиптә әлеге затка карата иминият килешүенең калган гамәлдә булу срогына пропорциональ өлешендә әлеге затны иминләштерүгә бәйле түләнгән иминият премиясен иминятләштерүчегә кире кайтара.

7. Иминият очраклары булып түбәндәгеләр тора:

1) иминләштерелгән затның муниципаль вазыйфаны биләгән чорда, шулай ук муниципаль вазыйфа биләгәндә имгәнүләр, травмалар яки авырулар нәтиҗәсендә бер ел эчендә вафат булуы;

2) муниципаль вазыйфаны биләп торган чорда, шулай ук муниципаль вазыйфаны биләү чорында алынган имгәнүләр, травмалар яки авырулар нәтиҗәсендә муниципаль вазыйфадан азат ителгәннән соң бер ел дәвамында иминләштерелгән затка инвалидлык билгеләү;

3) муниципаль вазыйфаны биләү чорында иминләштерелгән затның имгәнүе яисә травма алуы;

4) иминләштерелгән затның медицина бәяләмәсе нигезендә сәламәтлек торышы буенча, эшкә алучы (эш бирүче) вәкиле инициативасы буенча муниципаль вазыйфадан азат итеп хезмәт килешүен (контрактын) өзүгә нигез булган һәм инвалидлык билгеләүгә бәйле булмаган авыруга дучар булуы.

8. Иминләштерелгән затларга (файда күрүчеләргә) түләнә торган иминият суммалары күләме муниципаль вазыйфаны биләүче затның айлык акчалата бүләкләреннән (алга таба ─ бүләкләү) чыгып билгеләнә.

9. Иминият очраклары килеп туган очракта иминият суммалары түбәндәге күләмдә түләнә:

1) иминләштерелгән зат муниципаль вазыйфаны биләгән чорда вафат булган очракта, шулай ук муниципаль вазыйфа биләгәндә алынган имгәнү, травмалар яки авырулар нәтиҗәсендә вазыйфадан азат ителгән очракта бер ел дәвамында – 26,25 бүләкләү. Әлеге иминият суммасы файда күрүчеләргә тигез өлешләрдә түләнә;

2) иминләштерелгән затка муниципаль вазыйфаны биләгән чорда шулай ук муниципаль вазыйфа биләгәндә алынган имгәнү, травмалар яки авырулар нәтиҗәсендә вазыйфадан азат ителгән очракта бер ел дәвамында инвалидлык билгеләнгән очракта:

I төркем инвалидка -17,5 бүләкләү;

II төркем инвалидка -12,25 бүләкләү;

III төркем инвалидка -10,5 бүләкләү;

3) иминләштерелгән зат муниципаль вазыйфаны биләгән чорда авыр имгәнү яки травма алган очракта ─ җиде бүләкләү, җиңелчә имгәнү яки травма алган очракта – 1,75 бүләкләү. Тиешле иминият суммасы түләнә торган имгәнүләрне һәм травмаларны авыр яисә җиңелчә төргә кертү «Хәрби хезмәткәрләрнең, хәрби җыеннарга чакырылган гражданнарның, Россия Федерациясе эчке эшләр органнарының, янгынга каршы дәүләт хезмәтенең гади һәм җитәкче составының, җинаять-башкарма системасы учреждениеләре һәм органнары хезмәткәрләренең,

Россия Федерациясе Милли гвардиясе гаскәрләре хезмәткәрләренең тормышын һәм сәламәтлеген мәҗбүри дәүләт иминләштерүе турында»1998 елның 28 мартындагы 52-ФЗ номерлы Федераль законда_билгеләнәгән авыр яки җиңелчә төргә кертелгән имгәнүләр (яраланулар, травмалар, контузияләр) исемлеге нигезендә гамәлгә ашырыла.

4) иминләштерелгән зат медицина бәяләмәсе нигезендә сәламәтлек торышы буенча, эшкә алучы (эш бирүче) вәкиле инициативасы буенча биләгән муниципаль вазыйфасыннан азат ителеп һәм вазыйфадан җибәрелепп, хезмәт килешүен (контрактын) өзүгә нигез булган һәм инвалидлык билгеләүгә бәйле булмаган авыруга дучар булган очракта - 8,75 бүләкләү.

Муниципаль вазыйфаны биләгәндә яисә муниципаль вазыйфадан азат ителгәннән соң бер ел узганчы, иминләштерелгән затка медик-социаль экспертиза федераль учреждениесендә кабат таныкланган вакытта инвалидлык төркеме арттырылса, иминият суммасы яңа билгеләнгән инвалидлык төркеменә туры килә торган бүләкләүләр саны һәм элеккеге инвалидлык төркеменә туры килә торган бүләкләүләр саны арасындагы аерма суммасына арта.

Иминият очрагына бәйле рәвештә иминләштерелгән затка иминият суммасы түләнгән булса, ел дәвамында иминият очрагы барлыкка килгән көннән башлап һәм аана турыдан-туры бәйле рәвештә аның сәламәтлек начарая барса яки ул вафат булса, элек түләнгән иминият суммасын (иминият суммаларын) чигереп, өстәмә иминият түләве башкарыла.

Һәр иминләштерелгән зат өчен түләнә торган иминият премиясе күләме иминият килешүе белән билгеләнә һәм иминләштерелгән затны иминиятләштерү килешүе төзү вакытына билгеләнгән бүләкләүнең 8,75 процентыннан артмаска тиеш.

10. Түбәндәге иминият очракларында иминиятче мәҗбүри дәүләт иминияте буенча иминият суммасы түләүдән азат ителә:

1) иминләштерелгән затның суд тарафыннан билгеләнгән тәртиптә иҗтимагый куркыныч дип танылган гамәл кылуы нәтиҗәсендә булса;

2) иминләштерелгән затның алкоголь, наркотик яки агулы матдәләр белән исерүе суд тарафыннан билгеләнгән булса;

3) иминләштерелгән затның үз сәламәтлегенә белә торып зыян салуы яисә үз-үзенә кул салуы суд тарафыннан расланган булса.

Иминләштерелгән затның вафат булуы үз-үзенә кул салуга китереп җиткерү нәтиҗәсе булган һәм ул суд тарафыннан раслаган очракта, иминиятче иминият суммасы түләүдән азат ителми.

Иминият суммасын түләүдән баш тарту турындагы карар иминиятче тарафыннан кабул ителә һәм иминләштерелгән затка (файда күрүчегә) һәм иминләштерүчегә күрсәтелгән баш тарту сәбәпләренең мәҗбүри дәлилләнгән нигезләмәсе белән язма рәвештә хәбәр ителә.

11. Иминият түләүләрен гамәлгә ашыру иминләштерүче тарафыннан иминләштерелгән затның (файда күрүченең) гаризасы һәм иминләштерүче биргән иминият очрагы килеп чыгуын раслый торган документлар нигезендә башкарыла.

Иминият түләвен гамәлгә ашыру турында карар кабул итү өчен кирәкле документлар исемлеге, аларны бирү һәм карау тәртибе иминият килешүе белән билгеләнә.

Иминият суммаларын түләү иминият килешүләренең башка төрләре буенча иминләштерелгән затларга тиешле суммаларга бәйсез рәвештә башкарыла.

Иминият суммалары иминиятләштерүче тарафыннан иминләштерелгән затларга (отышлы сатып алучыларга) иминият килешүендә билгеләнгән ысул белән тиешле суммаларны күчерү юлы белән түләнә.

Иминият суммаларын түләү иминләштерүче тарафыннан күрсәтелгән түләү турында Карар кабул итү өчен кирәкле документларны алган көннән 10 көн эчендә башкарыла.

12. Иминият килешүенең гамәлдә булу срогы дәвамында иминләштерелгән затларның акчалата бүләкләве, шулай ук аларның саны үзгәрсә, күрсәтелгән шартларга бәйле рәвештә алынмаган яки артык алынган иминият взнослары суммасы өстәмә рәвештә түләнергә яки кире кайтарылырга тиеш. Иминият килешүен төзегән якларның килешүе буенча, әлеге сумма иминият килешүенең чираттагы чорына иминият взнослары күләмен билгеләгәндә исәпкә алынырга мөмкин.

Иминият взносларын иминиятләштерүче тарафыннан кертү вакыты иминият килешүе белән билгеләнә.

13. Мәҗбүри дәүләт иминияте чыгымнарын финанслау Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты хисабына башкарыла.